СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. Центральная, д.35,
п.Мюд, 423063

Үзек урам,35 енче йорт
Мюд авылы , 423063

Тел.: (84344) 4-04-33, факс: (84344) 4-04-33. E-mail: Mud.Aks@tatar.ru, http://aksubayevo.tatarstan.ru

# КАРАР

№ 93 29.08.2025 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы 22.01.2018 № 53а карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеген төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2014 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы « Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, «Территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләренә өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 19.07.2022 N 01-16/5057 хатына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында»22.01.2018 № 53а карарына кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча http:// Aksubayevo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, шулай ук җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.

Мюд авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Т.В. Зюзина

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" Р 06-644/13 СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1603001430 ОГРН 1021605357476 РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Расланган
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
Советы карары белән
29.08.2025 ел № 9 3

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында" 22.01.2018 № 53а карарына кертелә торган үзгәрешләр.

1. III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә::

"Юл сервисы объектларын карап тоту

92.1 юл сервисы объектлары - юл хәрәкәтендә катнашучыларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән биналар, төзелешләр, корылмалар, башка объектлар (автозаправка станцияләре, автостанцияләр, автовокзаллар, кунакханәләр, кемпинглар, мотельләр, җәмәгать туклануы пунктлары, техник хезмәт күрсәтү станцияләре, шуңа охшаш объектлар, шулай ук аларның эшләве өчен кирәкле ял итү һәм транспорт чараларын кую урыннары).

92.2 автомобиль юллары буенда яисә алар янында урнашкан сервис объектлары өчен бүленгән территорияләрне карап тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

92.3 юл буе сервисы объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлегенә керә:

-уңайлы хәрәкәт итү өчен каты өслек;
-территорияне яктырту, архитектура-декоратив яктырту;
- урнаштыру һәм карап тоту таләпләрен үтәгән бәдрәф кабиналары;
- чүп савытлары һәм кече контейнерлар;
- яшелләндерү (газон, чәчәкләр) һәм яшелләндерү участокларын саклау элементлары (коймалар).

92.4 Сервис объектларын һәм аларга якын территорияләрне урнаштыру һәм карап тоту таләпләренә керә:

-сервис объектларына керү-чыгу юллары, керү юллары күчеш-тизлек полосалары белән җиһазландырылырга тиеш;;

- -сервис объектларының күчеш-тизлек полосалары һәм территорияләре тышкы яктырту белән җиһазландырылырга тиеш;
- - хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгына чыгучы юлдан гамәлдәге су чыгару системасы белән бәйләнгән озынча суүткәргеч тәэмин ителгән булыр иде(чыгу юллары астына су үткәрү торбалары салынырга тиеш).;
- - хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгының һәм аңа таба чыгу юлларының буй авышлыгы юлның капма-каршы ягына юнәлдерелергә тиеш. Түгәрәклләнү радиуслары чикләрендә ул 20 % тәшкил итәргә тиеш.
- - мәйданчык һәм аңа чыгу юллары автомобиль юлы белән бертигез тотрыклы камилләштерелгән катламга ия булырга тиеш;
- - ГОСТ Р 52289-2019 «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл билгеләрен, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлеш бирүче җайланмаларны куллану кагыйдәләре» таләпләре нигезендә юл хәрәкәтен

оештыруның техник чаралары булу.

- - функциональ билгеләнеш буенча хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясендә, шул исәптән, санитария-гигиена зонасы булырга тиеш;
- - тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан каралган булырга һәм бирелгән техник шартларга туры китереп файдаланылырга тиеш;

-юл буе сервисы объектларының транспорт чараларын кую урынында «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын бушлай кую өчен урыннар бүлеп бирелергә тиеш; эксплуатацияләү һәм тоту процессында сервис объекты территориясендәге кимчелекләрне бетерү ГОСТ Р 59292-2021 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Җәйге тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» һәм ГОСТ Р 59434-2021 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кышкы тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль методлары" нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.